Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Косяково авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**18 ноябрь 2023ел** **№2/2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Косяково авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Норлат авыл җирлеге торак пункты, Косяково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш, хәрби бурычны үтәгәндә имгәнгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ булган һәр кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

2) Косяково авылының Үзәк урамындагы күпер корылмасын ремонтлау, төзекләндерү һәм тоту, инерт материаллар сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) адреслары буенча кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче Саттаров И.М.